ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 14 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (2020 елның 25 декабрендәге 90-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 1 (I өлеш), № 36 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш), түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Эшкуарлык эшчәнлегенең салым салуның патент системасы кулланыла торган төрләре буенча индивидуаль эшкуар потенциаль алырга мөмкин булган еллык керемнең әлеге статья нигезендә билгеләнгән күләмнәре ел саен тиешле календарь елга билгеләнгән коэффициент-дефляторга индексацияләнергә тиеш.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 28 сентябрь
№ 85-ТРЗ